ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ

№ 1–2.
16 февраль, 2022 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ > 3

ТАТАР ГЕНЕРАЛЫ > 7

ЯЛ ИТКӘНДӘ > 8

Автор фотосы

СИН – МИНЕМ ҖАНЫМНЫҢ ЯРТЫСЫ

Бервакыт редакциягә олы яшьтәге, таякка таянган бер бабай килеп керде. Ул Кукмарага «карлыгач»ына дарулар алырга килгән икән. Өлкәннәрнең бер-берсенә «карчык», «әбисе», «әнисе», «әтисе» кебек сүзләр белән эндәшкәннәрен ишеткән бар иде, әмма «карлыгачым» сүзе тагын да ягымлы, мөлаем булып ишетелде. Шул вакытта, минә райондашларыбыз арасында нинди гүзәл парлар бар, дип сокланган идек.

Күптән түгел тагын бер шундый матур гаилә белән танышырга туры килде. Кукмарадан Зиннур абый тормыш иптәше Фәризә апаны җитәкләп кенә йөртә, «син – минем җанымның яртысы» дип, яратып эндәшә. Узган атнада алар район ЗАГС бүлегендә бергә гомер кичерүләренең 60 еллыгын билгеләп үтте. Эх, һәркемгә дә әлеге өлкәннәр кебек матур картлык насыйп итсә иде…

Юбилярларны котларга якыннары, туганнары җыйналды, район башлыгы урынбасары Резеда Гаянова, газ оешмасы җитәкчесе Искәндәр Фәйзрахманов килде һәм җылы теләкләрен җиткерде.

– Элек аерылышу бик юк иде, бер-берсен табышкан парлар гомергә бергә булырга дип кавышты. Хәзер исә мөнәсәбәтләргә җиңел карыйлар, яшьләр авырлыклар туган вакытта тиз кызып китеп, карарлар кабул итәләр. Шуңа күрә иң мөһиме – сабырлык кирәк. Юкка гына сабыр төбе – сары алтын, димиләр. Тормыш юлы гел туры гына бармый, сикәлтәле, тайгак җирләре дә була, шул вакытта үзеңне кулга аласы, – ди өлкәннәр, 60 ел бергә гомер итүнең серен ачып. – Бу тормышта шөкер итеп яшәргә кирәк.

> 7

Яңалыклар

Бер гасырлык гомер

Тыл ветераны, 100 яшен тутырган Оркыя апа Минһаҗева Минзәлә шәһәрендә гомер кичерә. Туган көне уңаеннан шәһәр башлыгы урынбасары Роза Салдаева, юбилярның өенә барып, аны район башлыгы Айдар Сәлахов исеменнән котлап, бүләк бирде. Россия Президенты Владимир Путин һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның котлау открыткаларын тапшырды.

Хәзерге көндә Оркыя апа үз йортында уллары тәрбиясендә гомер кичерә. Тумышы белән ул элеккеге Калинин, хәзерге Актаныш районының Пучы авылыннан. 1960 елда тормыш иптәше, балалары белән бергә Минзәләгә күченеп киләләр.

Озын гомерлелекнең сере – актив тормыш рәвеше алып бару, режим буенча дөрес туклану, ди уллары әниләре хакында. Оркыя апа бүген дә үз акылында, хәтере яхшы, тормыш-көнкүреш вакыйгалары, ил яңалыклары белән даими кызыксына.

Тормыш иптәше Барый белән алар биш ул тәрбияләп үстерәләр. Барый абый һәм ике улы инде күптән гүр иясе. Юбилярның хәзерге көндә 5 оныгы, 6 оныкчыгы һәм оныкчыкларының да ике баласы бар.

(Дифиза НУРИЕВА. «Минзәлә-информ»)

Җылы очрашу

Апас районының Коштаулы мәдәният йортында бик җылы очрашу узды. Кичәгә республика күләмендә танылган шәхесләребез кайтты. Очрашу «Ислам динен кабул итүгә – 1100 ел» дигән темага багышланган иде. Ислам – кешеләрне бер-берсенә ярдәм итәргә, хөрмәт итәргә, олыларны олыларга өйрәтүче, кыскача әйткәндә, миһербанлык орлыгы сибүче дин. Шушы гамәлләрне исәпкә алып, Казандагы Апас якташлык җәмгыятенең вице-президенты Наил абый Галиуллин һәм Рәшит абый Байбиков авылыбызда балаларга гарәпчә укырга, ислам динен якыннан өйрәнү өчен дәресләр үткәрү мөмкинлеге тудырдылар. Дәресне авылдашыбыз Гөлназ Латыйпова үткәрде. Моның өчен оештыручыларга барлык әти-әниләр исеменнән зур рәхмәтебезне белдерәбез!

Бу очрашуның файдалы тагын бер ягы булды. Танылган балалар хирургы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган табибы Рәшит абый Байбиков балаларга диспансеризация үткәрде.

Тәскирә ХАФИЗОВА

«ӘНИ» ДИП ӘЙТМӘСӘГЕЗ ДӘ БУЛА»

Автор фотосы

Кече Сон мәктәбе директоры Тәнзилә Сәйфуллина Нәсимә Сәйфи кызын 80 яшьлек юбилее белән котлый.

Сүзем Мамадыш районының Кече Сон авылында гомер итүче, туры сүзле, таләпчән ветеран укытучы Әхмәтханова Нәсимә Сәйфи кызы турында.

Ул 1942 елның 25 гыйнварында Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылында дүрт баланың өлкәне булып дөньяга килә. Әтисе Сәйфетдин абый шофер булып эшли, ә әнисе Халисә апа – гади колхозчы. Ул бик чиста, пөхтә, уңган-булган хатын була, балаларын да шулай тәрбияли, тәртипкә, чисталыкка өйрәтә.

Туган авылында урта белем алганнан соң, пионервожатый булып мәктәпкә эшкә урнаша. Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетына читтән торып укырга керә. Туган мәктәбендә тарих, география, җәмгыять белеме фәннәрен укытырга туры килә аңа.

Тырыш, җыр-биюгә оста Галимҗанга тормышка чыга Нәсимә апа. Башка чыгып, үз нигезләрен төзиләр. Бер-бер артлы мәхәббәт җимешләре Нурзия белән Фәнис дөньяга килә. Матур гына яшәп ятканда, аварияда Галимҗан абый үлеп китә. Ике яшьлек кызы, бер айлык улы белән тол кала ул. Яшәргә, балаларны аякка бастырырга кирәк.

Балалар югары сыйныфка җиткәч, Казан шәһәренә юл ала, тулай торакка тәрбияче булып урнаша. Шуннан бүлмә дә бирәләр. Кызы белән малае үзләре тормыш коргач, әниләре бәхетен яңадан сынап карарга балаларыннан хәер-фатиха ала. Шулай итеп, Нәсимә апа 1989 елның җәендә безнең Кече Сон авылындагы, хатыны үлеп, алты бала белән тол калган Фәйзрахман абыйга кияүгә чыга. Ул вакытта аңа кырык җиде яшь була. Әле Фәйзрахман абыйның әнисе дә исән, уникe ел каенана белән яшәргә дә өлгерә. Тормыш иптәше газовик булып эшли, акыллы, кулыннан килмәгән эше юк. Бер-берсен аңлап, санлап, хөрмәтләп, утыз ел гомер итәләр. Моннан ике ел элек бакыйлыкка күчкән Фәйзрахман абыйны Нәсимә апаның сагынмаган, юксынмаган көне юк.

Нәсимә Сәйфи кызы монда килгәндә, Фәйзрахман абыйның төпчек кызы 5 нче сыйныфта укый, ике баласы гына тормыш корган була, калганнарын икесе бергә урнаштыралар. Алар гаиләсендә, монысы Нәсимә балалары, монысы Фәйзрахманныкы, дигән сүз булмады. Барлык балалар да икесенеке, кадерле иделәр. Килгән көннән балаларның олысы-кечесе, зурлап, «әни» дип эндәштеләр. Нәсимә апаның: «Әни» дип әйтмәсәгез дә була», – дигән сүзенә каршы олы килен: «Ничек әйтмәсеннәр инде?!» – ди.

Укытучылык эшчәнлеген дәвам итә Нәсимә апа, ике ел Югары Сон мәктәбендә география фәнен укыта, башлангыч мәктәптә урын бушагач, Кече Сон башлангыч мәктәбендә эшли башлый. Белемле, төпле фикерле, акыллы укытучыны коллектив та, укучылар да, авыл халкы да хөрмәт итә. Лаеклы ялга чыканнан сон, ирле-хатынлы икесе дә дин юлына басалар, биш вакыт намазларын калдырмыйлар.

Хәзерге көндә Нәсимә апа үзе генә гомер итә, ләкин ул ялгыз түгел. Аның һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер булган күршеләре, гел кайтып, хәлен белеп торучы балалары бар. Әле менә шушы арада гына узган сиксән яшьлек юбилеена да барлык балалары җыелды. «Туган көнең белән, әнием», – дип биргән бүләкләренә сөенеп, рәхмәт укый, балаларының, оныкларының исәнлегенә дога кыла ул.

Мәктәп директоры Сәйфуллина Тәнзилә Мирсәет кызы аның белән эшләгән вакытларын сагынып искә ала. «Миңа Нәсимә апа икенче әни булды, кешеләрне аңларга, дөрес фикер йөртергә, тормыш итәргә, тәмле ризыклар пешерергә өйрәтте, мин аңа бик рәхмәтле, алдагы көннәрә дә бәхетле булсын», – ди. Бу теләкләргә кушылып, без дә аңа сәламәтлек, күңел тынычлыгы, бәхетле картлык телибез.

Ләйсирә ЯРУЛЛИНА,
Кече Сон мәктәбе укытучысы

Әле китап укыйлар

Сиксәненче елларда Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», Аяз Гыйләҗевның «Ягез, бер дога», Гариф Ахуновның «Хәзинә», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» кебек китапларын чиратка язылып укыдылар.

Заманалар үзгәрде, вакыт җилләре – килеп туган үзгәрешләр китаплар дөньясына да төзәтмәләр кертте: компьютерлар, йөзләгән программалы телевидение, айфоннар, интернет язмача басмаларны кысрыклады, әмма авыл китапханәләренә йөреп, китап, көндәлек матбугат басмалары – газета-журнал укырга яратучылар бар әле.

Күзкәй китапханәсе каршында эшләүче «Хәтирә» клубында 30 ел буе китапханәгә йөреп, китап алып укыган Рәзилә Муллахмәтованың бенефисын үткәрдек. Күргәзмә киштәгә соңгы дүрт елда «Иң актив китап укучы» исемлеген әйдәп баручы Рәзилә укыган китапларны тезеп куйдык. Күргәзмә «Минем беренче китапларым», «Гаилә укулыннан», «Укырга тәкъдим итәм» дигән бүлекләрдән тора иде. Өстәлдә – китап укучы формулярының зурайтылган макеты. Аның белән һәркем кызыксынып танышты. Бенефиска Рәзилә Муллахмәтова яратып укыган Зифа Кадыйрованың «Сагынырсың – мин булмам» әсәренең герое Сөмбел дә «килгән иде». Китап герое белән Зифа Кадыйрова әсәрләре, алардагы образлар, тормыштан алынган язмалар турында әңгәмә-фикер алышу, бәхәсләр җанлы барды.

Укыган күпсанлы китаплардагы геройлар язмышы, кыен хәлләр чоңгылыннан чыгу юллары, тетрәндергеч мизгелләр чишелеше Рәзиләгә тормышында ярдәм иткәнме? Бенефиста катнашучылар мондый сорауны да бирделәр.

– Белеп торасыз, мин ике баламны кочаклап, бик яшьли тол калдым. Өебез кечкенә, иске. Утын әзерләп ягарга кирәк. Кешегә зарланып йөреп кенә дә йөрәккә дәва табып булмый. Чарасызлыктан диммме инде, китап укырга тотындым. Мин моны бер дә гайре табигый хәл димим, китап укымаучылар аңламыйдыр аны. Төннәр буе китап укый торган чаклар булды, – ди Рәзилә. – Шундагы геройлар язмышы белән яшәп, үземне борчыган сорауларга җавап табам, яшәргә өйрәнәм. Хәзер вакыт та бар, китаплар да күп. Хатын-кыз язучыларның әсәрләрен укырга яратам. Алар күңелне тирәнрәк аңлый сыман. Хәзер инде ике оныгымны иярттеп килә китапханәгә, аларга китап сайлашам.

Кечкенә гәүдәле, чикләвек төше кебек тере Рәзилә авыл урамында еш очрый. Әле сөт сатарга чыга ул, я нидер күтәреп кайтып килә. Чөнки улы Инсаф белән алар яңа йорт җиткереп керделәр. Аны матурлыйсы, кирәк-ярагын аласы бар. Авылыбызда сыер асраучылар бармак белән санарлык кына калды. Сыңар канатлы Рәзиләбез сыер асрый, күпме кешене сөт, эремчек белән тәэмин итеп тора. Кем белә, бәлки мондый талмас йөрәк көчен, дөньядан ямь-тәм табып, яшим дип яшәүне шул укыган китапларының геройларыннан өйрәнгәндер ул, йокысыз төннәрендә, инде нишләргә, дигән чакларында шулардан җавап тапкандыр. Һәрхәлдә, оста пешекче, җитез хуҗабикә Рәзиләбез бүген балаларының, оныкларының җылысын тоеп тулы тормыш белән яши.

Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА,
Күзкәй китапханәсе мөдире.
Тукай районы

Автор фотосы

ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ

2021 ел барыбыз өчен дә күңелсез вакыйгаларга бай булды. Ә минем йөрәгемдә мәңге төзәлмәс яра, җанымда җуелмас югалту ачысы калдырды. Шушы яшемә кадәр янәшәмдә булган газиз әнием бакыйлыкка күчте. Ничә яшьтә булса да, адәм баласы күңеле белән әти-әни үлеменә риза түгел икән...

Газизләрем 65 ел парлы гомер кичереп, икесе дә 91 яшькә җитеп дөнья куйдылар. Мин бик сирәк кешеләргә генә эләгә торган бәхетне татыдым: 62 яшемә кадәр алар янәшәсендә бала булып яшәдем! Кирәк тә булдым, терәк тә булдым кебек. Балалык бурычым да үтәлгәндер сыман. Тик әнине сагындырган йокысыз төннәр уйландыра... Мин барысын да эшләп бетердемме? «Җәннәт әниләрнең аяк астында», – диләр, оҗмах ишекләре миңа ачылырмы? Олы йөрәкле әниемне кадерли алдыммы, бәяләп бетердемме икән? Ә бит ул, чыннан да, бәяләп бетергесез олуг зат, зыялы шәхес иде.

Әнием Шәйхетдинова (Зарипова) Рәшидә Сәләхетдин кызы 1930 елның 28 ноябрендә Исәнбай авылында өченче бала булып дөньяга килә. Күпбалалы гаиләдә алар дүрт кыз, бер малай үсәләр. Башка яшьтәшләре кебек, кечкенәдән үк тормышның ачысын да, төчесен дә татый әнием. Җидееллык мәктәпне уңышлы тәмамлап, Минзәлә көллиятендә ул чорның иң абруйлы саналган укытучы һөнәрен үзләштерә. Дипломлы яшь белгеч башта районыбызның Үтәгән авылында, соңрак Исәнбайдан ерак булмаган Алга авылында башлангыч сыйныф укучыларына белем бирә, шунда ук мөдир вазыйфасын да башкара.

Сугыштан соңгы авыр еллар... Тик яшьлеккә алар киртә була аламы соң?! Ул чордагы аулак өйләр, су буе уеннары, чишмә буйлары халык теленнән бүген дә төшми. Әнием дә үз мәхәббәтен таба. Данлыклы Исәнбай МТСында шофер булып Девятерня авылыннан килеп эшләүче Нургаян Шәйхетдинов белән гаилә кора. Балачакларын сугыш урлаган, бер үк кичерешләр, бер үк хисләр белән янган бу ике җан бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яшиләр. Зур тырышлык, авырлык, әмма хәләл көч белән үз дөньяларын коралар. 1955 елда, тормышларына ямь өстәп, апам Ләлә, ике елдан соң мин төпчек бала булып туганмын.

Хезмәт елы

Әнием 1958 елдан хезмәт биографиясен Девятерня җидееллык (1962–1963 уку елыннан сигезьеллык) мәктәбендә дәвам итә. Бөтен барлыгын, тырышлыгын куеп балалар йөрәгенә юл сала, күңелләрен яулый. Белем бирә, туган телгә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли. Хезмәтне яратырга өйрәтә. Авыл халкы әйтүенчә, ул чор укытучылары балаларга искиткеч игътибарлы, кешелекле, ярдәмчел булулары белән аерылып торганнар. Аларга һәрберсендә 25әр бала булган сыйныфларны бергә кушкалап та, икешәр смена укытырга да туры килгән, ләкин алар бервакытта да зарланмаган, сыкранмаганнар, үз эшләренең осталары булып, җан кушуы буенча эшләгәннәр. Миңа аларның искиткеч эшкә бирелгәнлеге, укучыга мәхәббәте, ихтирамы, үз фәннәрен тирәнтен белүе, дәрес бирү осталыклары күп кенә хәзерге укытучыларга эталон хезмәтен үтәр иде кебек тоела.

Мәктәп дирекциясе, өлкән сыйныфларга татар теле һәм әдәбияты укытучысы кирәк булгач та, нәкъ менә яшь, энергияле, укыту өлкәсендә тәҗрибә туплаган Рәшидә Сәләхетдин кызына туктала. Мин инде, гомерем буе мәктәп тормышы белән яшәгән кеше буларак, әниемнең ул чактагы халәтен аңлыйм. Яңа фән буенча белемнәрне нигезле итеп бирү җиңел бирелмәгәндер, ләкин ул барлык кыенлыкларны җиңеп, озакламый мәктәптә иң абруйлы укытучыларның берсенә әверелә. Татар теле һәм әдәбияты кабинетын тиешенчә җиһазлый, дәрестән тыш балалар белән күп эшли, кичке мәктәптә укыта, җәмәгать эшләре буенча күп төрле эш башкара. Озак еллар мәктәпнең профсоюз оешмасын җитәкли. Ул чорда профсоюз оешмасының дәрәҗәсе югары: ул – дирекциянең таянычы, ә укытучыларның яклаучысы була. Мин әниемнең, ул чор укытучыларының олы хезмәте турында «Девятерня мәктәбенең йөз еллык тарихы» китабында тасвирладым һәм бу китап әнием һәм үз укытучыларым хөрмәтенә чыгарылды да.

> Инде олыгаеп, лаеклы ялга киткәч тә, әнием һәрвакытта мәктәп тормышы белән кызыксынып яшәде. Балаларым – оныклары Булат һәм Алисәнең уңышларына балаларча сөенде. Мәктәпнең ирешелгәннәре аңа горурлык, җан рәхәте бирә иде. Мин дә үземнең педагогик эшчәнлектәге күп уңышларым белән әниемә, үземнең укытучыларыма бурычлы икәнемне бөтен барлыгым белән аңлап яшим.

Инде олыгаеп, лаеклы ялга киткәч тә, әнием һәрвакытта мәктәп тормышы белән кызыксынып яшәде. Балаларым – оныклары Булат һәм Алисәнең уңышларына балаларча сөенде. Мәктәпнең ирешелгәннәре аңа горурлык, җан рәхәте бирә иде. Мин дә үземнең педагогик эшчәнлектәге күп уңышларым белән әниемә, үземнең укытучыларыма бурычлы икәнемне бөтен барлыгым белән аңлап яшим.

Укытучылар эшенә иң дөрес бәяне, минемчә, аның укучылары, әти-әниләр бирә. Күп еллар Девятерня мәктәбендә укытып, районда абруйлы укытучы булып җитешкән, Татарстанның атказанган укытучысы Галия Муратова әни турында: «Мин Девятерня мәктәбеннән тыш беркайда да татар телен һәм әдәбиятын укымадым, миңа мәктәбемдә Рәшидә апаның биргән белеме бөтен тормышым буенча җитте, зур уңышларга ирешергә ярдәм итте», – ди.

Әйе, ул чор укучылары бүген инде үзләре дә лаеклы ялда. Әниемне, башка мөгаллимнәрне һаман да хөрмәт белән, яратып искә алулары, җылы сүзләре йөрәккә сары май булып ята. 70 ел (!) элек әниенең укучысы булган Гөлсинә апа Гатауллинаның бәйрәм саен чәчәк, бал күтәреп килүләре, күңел җылысын салып бәйләгән оекбашларын бүләк итүләре әнине бик сөендерә, җанын эретә иде. Аяклары нык авыртса да, Гөлсинә апа әнине соңгы юлга озатырга да килде, укытучысы турында истәлекләрен яңартты. Санкт-Петербург, Калининградтан кайткан укучылары Роза Шаймәрданова, Хәмдия Тимершәехованың һәм башка бик күпләрнең үз укытучыларын онытмавы, хәл белешеп торулары, кешелеклелек, мәрхәмәт җитмәгән бу заманда, күпләрдә соклану хисе уятадыр. Ә мин, үз чиратымда, әниемә сөенечле мизгелләр бүләк иткән бу олы йөрәкле авылдашларыма чиксез рәхмәтле!

Озак еллар намуслы хезмәте өчен әниебез СССР Мәгариф министрлыгы тарафыннан «1976 елда социалистик ярыш җиңүчесе» билгесе, Татарстан АССР Мәгариф министрлыгы мактау кәгазе, район администрациясе, мәгариф бүлеге, мәктәп администрациясе бүләкләренә ия булды. Тыл һәм хезмәт ветераны исемнәренә, медальләргә лаек булып, тырыш хезмәтенең нәтиҗәсен күрү бәхетенә иреште.

Рәхәт чак

Әнием бик күп укый иде. Татар, рус, чит ил классик әдәбиятын яратып укыды, укыганнарын мавыктыргыч итеп иптәшләренә, туганнарына сөйли белде. Мин дә кич белән йоклар алдыннан аның сөйләгәннәрен, вакыт үткәнне дә сизмичә, әниемнең җылы кочагына сыенып тыңлый идем. Мәктәптә беренче югары белемле татар теле һәм әдәбияты белгече Зәйтүнә апа Ганиеваның бик укымышлы кеше булуы хакында еш искә алды. Үземдә дә укытучым Мәүгыйдә апа Айдарова белән әнием әдәбиятка карата кызыксыну уятты дип уйлыйм. Соңрак күп еллар үткәч кенә мин әниемнең үзе өчен шигырьләр дә язуын белдем, кайберләрен күчереп тә алдым. Аның шигырьләрендә туган як матурлыгы, балалар якынлыгы, тормыш, яшәү яме чагыла.

Күзләр җитеп, ачы җилләр иссә,
Яме китә авыл, калаларның.
Еллар үтеп, яшьләр арткан саен,
Кадерлерәк була балаларың.

Шигырьләрен укыйм да әниемнең тавышын ишеткән кебек булам. Мине җылы кочагына алып, матур, йомшак тавыш белән мавыктыргыч итеп сөйли дә сөйли... Шулар искә төшеп, бәгырьне өзә.

Әнием туган авылы Исәнбайны бик сагынды. Җиләкле-чәчәкле Бай елга, Шомыртлы чокыры, Яман елга, Салкын чишмәләрне сөйләп, кешеләр, күршеләр хакында сорашып, кызыксынып яшәде. Туганнарының уңышлары белән горурланды, үзеннән иртәрәк бакыйлыкка күчкән, аларны сагынды, догасыннан калдырмады. Әнинең тагын бер күркәм гадәте бар иде: кайда гына яшәсә дә, күршеләре белән бик тату булды. Исәнбайдан Эльза Ижболдина, Девятернядан Гөлсинә Ситдыйкова да әниемне тыйнак, аз сүзле, ләкин турысын сөйли торган, хезмәт сөючән, үтә дә җаваплы, таләпчән, шул ук вакытта ягымлы һәм кайгыртучан зыялы кеше генә түгел, менә дигән күрше дә иде, дип искә алалар. Әниемнең төгәллеге, чисталык, тәртип яратуы, бакчага, чәчәкләргә, гөлләргә булган аерым мәхәббәте миңа да күчте. Яшелчәләре дә мул уңыш бирә иде әнинең, өстәвенә бик оста чигә, тегә иде... Күңеле матур иде шул газиземнең!

...Әнием миңа тормышта һәрвакытта үрнәк булды, ул бервакытта да уфтануны белмәде, соңгы елларында күп тапкыр инсульт кичереп ятканда да, оча сөяген сындырып, озак вакыт гипста булганда да зарлану ишетмәдем, бик сабыр, киң күңелле, игелекле кеше иде ул. Аның кем беләндер тарткалашканын, начар сүз сөйләгәнен хәтерләмим. Безне дә шулай өйрәтеп, тормышка яраклы кешеләр итеп тәрбияләделәр. Гомер буе аның күңел җылысын, яратуын тоеп, акыллы, төпле киңәшләренә таянып яшәдем, эшләдем. Әниемнең хезмәт юлы минем өчен маяк, өлге булды. Тормышта туры юл күрсәткәне өчен мин әниемә рәхмәтле, бурычлы!

...Әти дә, әни дә китеп бардылар. Берни алмадылар. Ә безгә гомеребез буена җитәрлек сабак, үгет-нәсыйхәт, хәер-дога калдырып киттеләр. Без – балалары кадерле кешеләребез өчен барысын да эшләдек кебек. Хәер, бу шулай булырга тиеш тә! Әти-әни турында кайгырту – балаларның төп бурычы. Әнием дә риза-бәхилләген калдырып киткәндер дип уйлыйм. Рәхмәт ахырында әниемә хөрмәт белән караучы авыл халкына, җитәкчеләренә, күп санлы укучыларына, авылыбызның шәфкать туташы Гөлчәчәк Мифтаховага, күршеләр Рамил һәм Камил Закировларга, тумышы белән Исәнбай кызы Зөлфия Фәйзуллинага, кызым-йолдызым Алисәмә, бабасының, әбисенең төп таянычы һәм булышчысы булган, кирәк булганда тәүлекнең теләсә кайсы вакытында кайтып булыша торган улым Булатка рәхмәтләремне җиткерәсем килә.

...Уйларымда көн саен иртән үз бүлмәсеннән әнием килеп чыгар кебек, ләкин аек акыл, ул кайтырга китмәде бит, дип әйтә... Урыны оҗмахта булсын! Теләкләрем әниемнең рухына дога булып барып ирешсен иде.

Илдус ШӘЙХЕТДИНОВ,
хезмәт ветераны.
Әгерҗе районы Девятерня авылы

Сынауларда сынмыйча яшәү

Буада яшәүче олы җанлы, киң күңелле ветеранны бөтен кеше хөрмәт итә. 1930 елда туган кыз балага шактый авырлыклар күрергә туры килә. Үз тырышлыклары белән дөнья көткән әтисе Зариф абый белән әнисе Мәгъсүмә апаның, «сез – байлар» дип, кечкенә генә кибетләрен тартып алалар.

Гөлшат урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан педагогия институтына укырга керә һәм химия, география, тарих фәннәрен укытырга рөхсәт биргән дипломга ия була. Гөлшат апа районның Норлат, Адав-Толымбай, Карлы авылларында балаларга белем бирә. Бераздан аны яңа ачылган интернат-мәктәпкә укытучы итеп эшкә чакыралар. Сабыйларны Гөлшат апа үзенекеләр кебек якын күрде, дәресләрдән соң алар белән төрле чаралар үткәреп мәш килде.

Мәрхәмәтлелек, кеше хәленә керә белү аңа нәселдән килгәндер. Әтисе Зариф абый да үзенең дүрт баласы өстенә туганнарының ятим калган өч сабыен да сыендыра бит. Яшьлегендә тырыш, уңган кызга димче җибәрүчеләр дә байтак була. Кыз күңелен Хәмит исемле чибәр егет яулап ала. Аның белән очрашып йөргәндә аяныч хәл була: тимер юлны аркылы чыкканда Хәмит, поезд астына элэгеп, бер аягының табанын, бер кулының бармакларын өздерә. Сәламәтлеге какшаса да, Гөлшат апа аны ташламый, ике гашыйк йөрәк кавыша. Тик гомере генә кыска була Хәмитнең, 57 яшендә яман чирдән үлеп китә.

Гөлшат апага 70 яшь тулган көнне зур кайгы кичерергә язган икән. 33 яшьлек кызы Лилияне җир куенына салалар. Бер атна эчендә авырып үлеп китә ул.

Олы яшьтә булса да, Гөлшат апаның кулыннан эш төшкәне юк. Арыдым дими, гел хәрәкәттә. Йорты артындагы бакчада төрле яшелчә, бәрәңге үстерә. «Узган җәйдә бер генә дә чүп үлән тотмадым, гел утап тордым», – ди. Помидор үсентесен дә үзе утырта. Намазын калдырмый, догалар күп белә, газета-журналлар укырга ярата. Үзенең сабырлыгы, башкаларны яратуы белән күпләргә үрнәк ул.

Әминә МИҢНУЛЛИНА.
Буа районы

СОКЛАНЫРЛЫК ГОМЕР ЮЛЛАРЫ...

Авылыбызда озак еллар имин, матур тормыш алып барган гаиләләр шактый. Шуларның берсе – Гөлсем белән Вәгыйз Хәмидуллиннар гаиләсе. Аларның тормышларында тиздән мөһим вакыйга – гаилә башлыгы Вәгыйз Хәмидулла улына – 90 яшь, бергә гаилә корып яшәүләренә 65 ел була. Һәр көн бер-берсен яратып торучы ике кеше өчен бәя биреп бетергесез тарихка әверелгән гомер бу.

Вәгыйз абыйның бала чагы авыр һәм катлаулы елларга туры килгән. Ул чакта берәүгә дә җиңел булмагандыр инде. Көтмәгәндә башланган сугыш бөтен тормышның астын өскә китерә. Фронтны азык-төлек, башка кирәк-яраклар белән тәэмин итүгә авыл халкының керткән өлешен бәяләп бетерә торган түгел. Хатын-кызлар, карт-корылар белән бергә балалар да иртәдән кичкә кадәр кырда иген икән, фермаларда терлекчелек продукциясе җитештергән. Сугыштан соң да әле халык зур авырлыклар белән тормышның очын-очка ялгап барган. Башка яшьтәшләре кебек үк, бик яшьли кул арасына керә башлаган Вәгыйз дә хезмәттә чыныгып үсә. Авылыбыздагы урта мәктәпне тәмамлап, гади колхозчы булып эшли башлый ул. Армиягә китә, илне дошманнардан саклый. Солдат хезмәтен үтәп, туган авылына кайта. Аннан соң баш-аягы белән авыл тормышына бирелә. Күңелдә матур уйлар, мәхәббәт, наз көткән чаклар! Авыл кызы Гөлсем белән әнә шул мәхәббәт кавыштыра аларны. Гөлсем бик тырыш, эшчән нәселдән булган егетне үзенә пар итә.

...Бәхет эзләп читкә омтылмый Хәмидуллиннар нәселе, гомер буе туган җиргә тугры калып, авылда хезмәт куялар. Вәгыйз абыйның әтисе Хәмидулла бабай колхозда эшли, мәктәптә атлар да карый, завхоз хезмәтен дә үз итә. Абыйлары Минтаһир колхозда ветврач, Рәхим сыерлар фермасына җитәкчелек итә, амбарда склад мөдире булып та эшли. Сеңлесе Солтания дә бик җитез, эшчән, тырыш. Ул тормыш иптәше Давыт белән төзү-монтаж участогында эшләп ала. Соңыннан дуңгызлар караучы булып эшкә урнаша. Минтаһир абыйсының улы Дамир «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемне лаеклы йөртә. Аның хезмәт юлы һәркемгә үрнәк булырлык: комсомол секретаре, кырчылык бригадиры, агроном, колхоз рәисе. Хәзер ул райондагы алдынгы крестьян-фермер хуҗалыгы белән җитәкчелек итә. Күп еллар авыл һәм район Советы депутаты булып сайланды. Әнә шундый тормыш баскычлары үткән кеше ул Дамир ага Хәмидуллин. Һәр урында да тырышып, булсын дип эшләп, үзләре җитәкләгән һәр коллективны югары хезмәт югарылыгына күтәреп, район һәм республика аренасына чыгарып, тарих битләрендә һәм кеше хәтерендә тирән эз кала торган итеп, тырышып эшли белә торган нәсел шул ул Хәмидуллиннар династиясе.

Ирле-хатынлы Гөлсем белән Вәгыйз Хәмидуллиннар да үз вакытында колхозның алдынгы хезмәтчәннәре булалар. Гөлсемә өч ел ат җигә, төрле эшләрдә эшли. Пенсиягә китәр алдыннан унбиш еллап механизаторларга ашарга пешерә, тапшырылган эшен намус белән башкара. Вәгыйз исә гади колхозчы булып та, кышын сыерлар фермасында терлек караучы, җәен көтүче, берничә ел ферма мөдире булып та эшләп ала. Вәгыйз ага – бик пөхтә, намуслы кеше. Гомумән бик әйбәт гаилә бу. Гади колхозчы гына булсалар да, заманына күрә менә дигән йорт салып керәләр, лапас тутырып мал-туар асрыйлар, кош-корт үстерәләр. Әлеге үрнәк гаиләнең күрке, юанычы һәм ышанычы булып, биш балалары үсеп җитә. Балалары кечкенәдән кул арасына кереп, эш сөючән, ихлас күңелле, итагатьле һәм тыйнак булып үсәләр. Гади хезмәтнең зур шатлык, чын бәхет китерүен яхшы аңлыйлар алар.

Менә шулай җай гына, көйле генә бара бу гаиләнең тормышы. Тик көннәрдән бер көнне, аяз көнне яшен суккандай, кызлары Гөлсара йөрәк чире белән авырый башлый һәм, озак та үтми, 36 яшендә баласын ятим калдырып үлеп китә. Тормыш юлында авырлыгын да, җиңеллеген дә күрергә, шатлык-сөенечләрдән

башлары әйләнгән мизгелләрнең рәхәтлеген дә, кайгы күлләренең тирәнлеген дә татырга туры килә аларга.

Гөлсем апа белән Вәгыйз абый гаиләнең барлык рәхәтлекләрен, байлыгын үз көчләре белән тырышып тапканнар һәм хәзер муллыкта яшиләр. Алар бер-берсен яшьтән үк белеп, яратып өйләнешкәннәр. Ягымлы, аралашучан, киң күңелләр. Туган-тумачалары, күршеләре, авылдашлары белән матур, тыныч, тату яшиләр. Гаиләдәге бәхетле, матур тормыш турында сөйләгәндә, Гөлсем апа ир белән хатынның холкындагы сабырлык, түземлекне беренче урынга куя.

– Дөнья булгач, төрле хәлләр булгалый. Иң мөһиме – сабырлык һәм кызган килеш бер-береңә күңелсез сүзләр әйтеп ташламау. Без, Аллага шөкер, тату яшәдек. Икәү булганда тормыш авырлыкларын кичерү дә җиңелрәк бит, бергәләп шатлану да рәхәт, – ди ул.

Сүзгә Вәгыйз абый кушыла:

– Ходайның биргәненә шөкер итеп, булдыра алганча тырышып эшләп, дөнья көттек. 25 ел әти-әни белән бергә яшәдек. Бик тырыш иделәр, мәрхүмнәр. Без эштә булганда балаларны әти-әни карады. Без аларга гомер буе рәхмәтле булдык. Тормыш иптәшем белән аңлашып, бер-беребезгә юл куеп, хөрмәт итешеп яшибез. Инде хәзер зур терлек-туар асрамыйбыз, ә кош-корттан өзелгәнебез юк. Алга таба да шулай, сәламәтлектә, парлашып яшәргә язсын, – ди ул.

Балаларның барысы да тормышта үз урыннарын тапканнар. Инде оныклары да үсеп җитеп, үз куышларын булдырырга өлгергәннәр. Балаларның игелеген күреп , онык-оныкчыкларга куанып яши алар хәзер. Хәмидуллиннар үзләренең тормыш рәвеше белән балаларына да, авылның яшь гаиләләренә дә матур үрнәк күрсәтәләр. Вәгыйз абыйны 90 яшьлек туган көне, юбилее һәм бергә гомер итүләренең 65 еллыгын да шатлыкта, исәнлектә-саулыкта каршылауларын һәм алга таба да имин тормышта яшәүләрен телибез.

Флёра ХӘЙРЕТДИНОВА.
Спас районы Иске Рәҗәп авылы

АЛМА АГАЧЫННАН ЕРАК ТӨШМИ...

Зәйнулла Һадиуллинны бүген дә олысы-кечесе хөрмәт белән искә ала. Кырык ике ел дәвамында Татарстанның Мамадыш районы «Таң» күмәк хуҗалыгын җитәкләгән, аны республика күләмендә алдынгы урыннарга чыгарган, «Октябрь Революциясе», «Хезмәт Кызыл Байрагы», «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнгән, СССРның сәламәтлек саклау отличнигы, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, сугыш ветераны ул.

Милләт сакчысы

Үзеннән соң сагынып искә алырлык зур эшләр, бүген дә үзе җитәкләгән Дүсмәт, Иске Комазан, Акман һәм Комазан Башы авылларын бизәп торучы күпсанлы биналар төзеп калдырган Зәйнулла абый.

Татар халкында «Алма агачыннан ерак төшми» дигән бик күркәм әйтем бар. Зәйнулла Һадиуллинның кызы Гөлфинур Дувалова да – бүген районның иң мөхтәрәм, гаять тырыш, татар милләте, татар теле дип җан атып йөрүче шәхесләрнең берсе. Узган гасырның туксанынчы елларыннан соң «үзгәреш җилләре» искән вакытларны күз алдына китереп утырабыз. Татар халкына аз гына булса да шатлык елмайган, милләтпәрвәр ватандашларыбызның тырышлыгы белән республикабызның суверенитет алган еллары.

– Шул елларда бер җир җимертеп эшләп алдым, ичмасам, – дип елмая Гөлфинур апа.

Әйе, укытучы, бигрәк тә татар теле укытучысы – милләт сакчысы ул. Бу сүзне, курыкмыйча, Гөлфинур апага карата да әйтә алабыз. Кызыл Тау мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып барганда, укучыларны белемле итү генә түгел, югары әхлаклы, зыялы, милли үзаңлы шәхес тәрбияләү максатын да куя ул. Шул максатны тормышка ашырыйм дип район күләмендә уздырылган ачык дәресләр, язучы-шагыйрьләребезгә багышланган бәйрәмкичәләр, бәйге-конкурслар, конференцияләр – боларны язар өчен үзенә бер китап кирәктер, мөгаен. Татар теле һәм әдәбияты кабинетын заманча бизәп, кечкенә генә булса да, милли музей да торгыза ул. Мәктәп кысасына гына сыймагач, Үзәк балалар китапханәсе һәм мәдәният йорты белән хезмәттәшлек итә башлый. Шәһәр мәктәпләре белән берлектә Габдулла Тукай, Шәйхи Маннур һәм башка язучы-әдипләребезнең туган көннәренә, юбилейларына багышлап әдәби-музыкаль кичәләр, шигырь конкурслары үткәрүдә, балалар белән спектакльләр куюда зур көч түгә.

Хезмәтенә күрә – хөрмәте

Укучылары күп тапкыр район күләмендә генә түгел, республика буенча да төрле дәрәҗәдәге әдәби-сәнгать конкурсларында, фән олимпиадаларында җиңеп чыктылар. Аларны иҗади шәхесләр итеп тәрбияләргә, йөрәкләрендә иҗат уаклары да кабызырга тырышты ул. Шәкертләре арасында мөгаллимнәр, сәнгать өлкәсендә хезмәт куючылар, җитәкчеләр бар. Гөлфинур Зәйнулла кызының йөрәгендә йөрткән иҗат уты, лаеклы ялга чыккач, саллы гына җиентыкларга әйләнеп, дөнья күрә башлады. Беренче шундый хезмәте Мамадыш районының «Таң» күмәк хуҗалыгы эшчәннәренә һәм аның легендар җитәкчесе Зәйнулла Һадиуллинга багышланган «Иң зур бәхет – хезмәттә» дигән китап булды. Аны халык һәм әдәбият сөючеләр бик җылы кабул итте. Ул – Мамадыш районының бер күмәк хуҗалыгы кысасында йөзәрләгән гади эш кешесенә багышлап чыгарылган беренче җыентык. Анда төрле елларда матбугат битләрендә басылган язмалар да бирелү китапның тарихи кыйммәтен тагын да күтәрде. Шунысы куанычлы: йөрәктә бер кабынган иҗат учагы торган саен көчәя генә бара. Гөлфинур апа да туган төбәгенең тарихы турында китап язу теләге белән архивларда эзләнә башлады. Нәтиҗәдә, берничә еллык эзләнүләрнең җимешләре булып, бер-бер артлы «Туган авылым – Акманым», «Комазан Башы – чишмә башы», «Дүсмәтем – гомер бишегем», «Чал тарихлы Комазаным» дигән зур күләмле һәм зәвыклы итеп эшләнгән китаплары дөнья күрде. Аларда әлеге авылларның тарихы Бөек Болгар, Идел буе Болгар дәүләте заманнарыннан ук башлап өйрәнелгән. Китапларда күпсанлы архив документлары урын алган. Алар тарихи-публицистик очерклар гына түгел, фәнни хезмәтләр югарылыгында эшләнгәннәр. Тарихи фактлар да кат-кат тикшерелгән һәм расланган. Акман, Дүсмәт, Комазан Башы һәм Иске Комазан авылларының бүгенге халкы, аларның күркәм эшләре турында да бик җылы һәм мавыктыргыч итеп бәян ителгән. Гөлфинур апа бу китаплары белән авылдашларын һәм якташларын тарихка кертеп кенә калдырмый, аларның хезмәтенә һәйкәл дә куя. Киләчәк буыннар алардан әби-бабалары турында горурланып укырлар, шөкер. Татарстан Язучылар берлеге һәм Мамадыш районы хакимияте әлеге китаплары өчен Гөлфинур Зәйнулла кызын Шәйхи Маннур исемендәге премия белән бүләкләде.

2019 елда Гөлфинур Зәйнулла кызы «Мамадыш муниципаль районы каршындагы казанышлар өчен» медаленә дә лаек булды. Гөлфинур Дувалова Россия һәм республика күләмендә үткәрелгән иҗади конкурсларда да актив катнаша. Россия күләмендәге иҗади һәм эзләнү-тикшеренү эшләре конкурсының «Әйт, авылым...» номинациясендә өлкәннәр яшь категориясендә җиңүче булды, аңа мактау грамотасы һәм кыйммәтле бүләк тапшырылды. Татар авылларын саклау һәм үстерү, буыннар бәйләнешен булдыруга үз өлешен керткәне өчен, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының Рәхмәт хатына лаек булды. Гөлфинур апа соңгы елларда, Мамадыш төбәге халык авыз иҗатын җыю белән шөгыльләнеп, күп санда риваятьләр, мөнәҗәтләр, йөремсәк мәзәкләр, халык җырлары һәм такмаклары, бәетләр туплады. Алар районыбызда ут күршеләр булып, туганлашып, ярдәмләшеп яшәүче төрле милләт вәкилләреннән язып алынган.

Халык авыз иҗаты әсәрләре – милләтнең иң кыйммәтле байлыкларының берсе ул. Алар әдәби һәм тарихи мирасыбызның гүзәл бер өлешен тәшкил итәләр. Фольклорны халыкның күмәк акылы, сәнгатькә сәләте тудырган. Форма ягыннан гасырлар дәвамында камилләшеп, сүз сәнгате югарылыгына күтәрелгәннәр. Гөлфинур апаның Мамадыш төбәге халык авыз иҗатын тупларга алынуы – үзе үк зур тәвәккәллек һәм изге гамәл. Инде дөнья күргән китаплары кебек, әлеге җыентык та гаять калын һәм саллы итеп эшләнгән. Китап үткәнне онытмаска, тормышның кадерен белергә, киләчәкне күрергә дә өйрәтә.

Вәрис ГАЛИ.
Мамадыш

Шигърият

ТАБИГАТЬ ГАЛИМӘСЕ

Филология фәннәре докторы, профессор Фирдәвес Гарипова истәлегенә

Казан артындагы Кодаш
Син туган авыл икән.
Туган җир һәрбер баласын
Шатланып кабул иткән.

Елга яры буендагы
Уйсу җирдә – үзәндә,
Рәхәтләнеп уйнагансың
Яшел хәтфә үләндә.

Инешендә тирләп-пешеп
Ташбаш балык сөзгәнсең.
Кече урманда беренче
Җир җиләген өзгәнсең.

Табигать байлыгы бик мул
Бездә борын-борыннан.
Халык бушлай нигъмәт җыйган
Урманнан һәм болыннан.

Бакчагыз яныннан гына
Алкып аккан инеш тә.
Авыл балалары өчен
Булган уен да, эш тә.

Шул инеш янында сезнең
Каз бәбкәләре үскән.
Вакытыгыз кечкенәдән
Файдалы булып үткән.

Ышна, Кәләпүш тавына
Син дә менгәнсең инде.
Үр ялауның кыенлыгын
Шунда белгәнсең инде.

Бала чакта тау менгәндәй,
Җиңдең фәннең үрен дә.
Синең исем урын алды
Күңелебез түрендә.

Матурлыгын күргәнсең син
Болынының, тавының.
Булачак галимә иткән
Сине туган авылың.

Таулар артындагы күл дә
Үзенә дәшеп торган.
Бала-чаганың коену
Теләге ташып торган.

Фән дә табигать күле күк,
Анда да шәп йөзгәнсең.
Күргән барлык атаманы
Син бер җепкә тезгәнсең.

Синең фәнни хезмәтеңдә
Язган һәрбер атама
Барысы бер җыелмада
«Табигать» дип атала.

Биш йөздән артык ул хезмәт
Каләмең аша үткән.
Фән докторы, профессор,
Галимә иdeң күптән.

Татарстан авылларын
Өйрәнгәнсең син башта.
Сине хәтерләп сөйлиләр
Безнең Имәнлебашта.

Салкын чишмәбезне үзең
Безгә килеп күргәнсең.
Авылымның гүзәллеген
Такыядай үргәнсең.

Синең сурәтләү аркылы
Белдем авыл турында.
Синең китаплар тарата
Безгә гыйлем нурын да.

Рухия АХУНҖАНОВА

ЗОЯ АБДУЛОВА:

Путинның котлавын көттем

Сарсаз-Баграж авылында яшәүче Зоя Михайловна 90 яшендә дә газета-журналларны бер хәрефен калдырмыйча укып бара, оекбашлар бәйли, йон эрли. Бөтен гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган, тырыш хезмәте белән укучылары, хезмәттәшләре, авылдашларының хөрмәтен яулаган педагог ул. Бүген аның укучылары республикабыз, районыбызның төрле тармакларында намуслы хезмәт итә.

Зоя Михайловна 1931 елда Мамадыш районы Иске Мочалкино авылында туган. Гаиләдә җиде бала булалар. Сугыш башланган елда мәктәпкә укырга керә. Ул елларны: «Язарга дәфтәр юк, иске китапның ак калган аралырына яза идек. Ике кешегә – бер дәфтәр, хәтта карандашны да урталай бүлеп бирәләр иде», – дип искә ала.

Әтисе Михаил Никифоров Бөек Ватан сугышына кадәр укытучы булып эшли. Сугышның беренче көннәреннән үк илебезне сакларга китә. Ул Сталинград блокадасын өзүдә катнаша. Шуның өчен аңа бер ай ял бирәләр. Туган авылына кайта, гаиләсе белән күрешә, яңадан Ватанны сакларга китә. 1945 елда, җиңү яулап, туган якларына исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп була Михаил Евдокимовичка. Аннан соң ул туган авылында хисапчы булып эшли.

Мәктәпне яхшы билгеләренә генә тәмамлаган Зояны Мамадыш педучилищесына имтиханнарсыз кабул итәләр. Кызны юллама белән Зәй районы Сарсаз-Баграж мәктәбенә математика укытучысы итеп җибәрәләр. Башта математика укыта, аннан башлангыч сыйныф укучыларына белем бирә. «Бер бүлмәдә икешәр сыйныфны бергә укыттык», – дип искә ала Зоя Михайловна ул чорларны. Ул гаилә бәхетен дә шушы авылда таба. 1956 елда Сарсаз-Баграж егете Василий белән гаилә корып җибәрәләр. Ул вакытта Василий Серафимович авыл Советы рәисе булып эшли. Читтән торып Алабуга педагогика институтының математика бүлеген тәмамлый. Ул авыл мәктәбендә күп еллар физика-математика укытучысы булып эшләде. Абдуловлар гаиләсендә дүрт бала үсте. Кызлары Роза алар юлын сайлады: шушы мәктәптә математика, информатика фәннәрен укытты.

Зоя апа хәзерге көндә кызы Роза белән кияве Алексей тәрбиясендә яши. Бу тормышның бик күп авырлыкларын күргән Зоя апа шундый якты, матур, мул тормышлы киләчәк турында хыялланырга да курыккандыр. Ә юбилее көнне, әйтерсең, ул ханбикә иде! Башына таҗ киеп, якыннары янәшәсендә балкып, рәхәтләнеп аралашты, үткәннәрне искә төшерде.

«Әниебез әле 90 яшендә дә газета-журналларны бер хәрефен калдырмыйча укып бара, кайчак күзлексез дә укый, оекбашлар бәйли, йон эрли», – ди кызы Роза.

«Путинның котлау открыткасын көтеп алдым. Аны юбилей узгач, икенче көнне дә кулыма алып кат-кат укыдым. Мине котлаучыларның барысына да рәхмәт инде, – ди Зоя Михайловна. – Илләр тыныч булсын, авырулар бетсен. Яшьләргә киңәшем – гомернең кадерен белегез. Күз ачып йомганчы уза да китә икән ул».

Клара ЕРМОЛАЕВА.
Зәй районы

«ЖИТЬ ДО СТА ЛЕТ!»

ШАМИЛ АГА ШӘКҮРОВ ҮЗЕ ЭШЛӘТӘ ТОРГАН ПЕЧӘН КИПТЕРҮ АГРЕГАТЫНА ШУЛАЙ ДИП ЯЗЫП КУЙГАН

Уйлар чынбарлыкка әйләнә дигәнне ишеткәнегез бардыр инде. Уйларыңны язып куйсаң, нәкъ шулай, син теләгәнчә булачак, диләр.

Зур Чынлы авылында яшәүче Шамил ага Шәкүров та үзенең бүгенге хәрәкәтчәнлеген, хәтеренең камил булуын Аллаһы Тәгаләдән әнә шулай язып сораган диярсең. Үзе ул: «Туксан туксан инде, күбрәк ястык сорый», – дисә дә, аңа карап бер дә ятып тора торган кеше дип әйтеп булмый. 90 яше белән котларга килүчеләрне дә ул рәхмәтләр укып, бөтен булган орден-медальләрен тагып каршы алды. Ә хезмәтен хөрмәтләп бирелгән мактау билгеләре күпсанлы аның. Шулай булмый мөмкин дә түгел, 12 яшеннән үгез, тана җигеп, җир сөрүләре турында сөйли авыл агасы.

«Үгез дә арый иде, арый да ята. Бер яттымы, аны инде тиз генә торгызырмын димә. Үзебез дә инде шуны гына көтеп тора идек. Үгезнең җылы корсагына сөялеп черем итеп ала идек. Моны күрсә, бригадир колак төбенә кундыра иде», – дип искә ала үзенең балачагын Шамил абый.

Авылга 1954 елда «Ильич утлары», ягъни электрлаштыру килә. Бу эш мәктәптә яхшы укыган Шамил агага йөкләнә. Әлегә кадәр читтән килгән монтерлар тарафыннан бер өйгә генә кертеп калдырган электр чыбыкларын авылның башка өйләренә дә тарталар алар. (Бу урында Шамил аганың бер оныгының бабасы хезмәтен бүген дә дәвам иттерүен әйтү урынлы булыр.) «Яңа, күнекмәгән эш бит әле, куркытты бераз, лампочкалар кабынырмы, сүнмәсме дигән шөбһә дә бар күңелдә. Чормадан эшне бетереп төшәбез дә кабызып карыйбыз. Өй хуҗалары белән бергә үзебез дә шатланабыз аннары, – дип сөйли игелекле эше турында электромонтер. – Аннан соң китте инде, авылдашлар телевизор, радиоалгыч алып кайтамы, миннән башка урнаштырмыйлар иде», – ди ул.

Тормыш иптәше белән 6 балага гомер бирәләр алар. Гомер дәвамында бер тракторга, комбайнга утырып эшләгән еллары да була. «Кызгана идем үзен, ул эшләргә тиешлене дә үзем башкарып куям. Әйбәт яшәдек, сабыр, мөлаем иде юлдашым. Әмма бу дөньядан иртәрәк китте шул», – дип көрсенә унынчы дистәне ваклый башлаган Шамил Шәкүров.

Гаиләләренә килгән авыр кайгыны күтәрәлмичә үлеп китә шул хатыны. Күптән түгел генә гаилә корган, беренче баласын алып кайтырга өзерләнгән оныкларына пневмония чире ябыша. Табиблар әнисенең гомерен коткарып кала алмаячакларын аңлагач, һич булмаса, бер җан яшәсен дип, баланы ана карыныннан ярып алалар. Тик бала церебраль параличлы булып туа. Аны үстерү, карау Шамил белән апаның кызлары Зөлфия, аның гаиләсе җилкәсенә төшә. Оныгы, аның ятим калган, шул ук вакытта аякка да баса алмаган бала өчен хәсрәтләнә-хәсрәтләнә әби кешенең үз саулыгына зыян килә.

«Мондый авырлыклар, билгеле, кешене тиле итәргә мөмкин. Мине дин коткарды», – ди Коръәндәге аять-сүрәләрне саны белән хәтерләгән Шамил абый.

Бер-берсен хөрмәтләгән, авырлыкларны тупланып, бер-берсенә ярдәм итешеп, шатлыкларны да уртак итә белә торган гаилә Шәкүровлар. Кияүләрнең дә шундыйларын үзенә яр итеп сайлаган бу гаилә кызлары. Бүген, мәсәлән, әтиләрен карап-тәрбияләргә дип бер кызы һәм кияве, үз йортларын калдырып, төп нигезгә күченгән. Яшәү өчен авылны гына сайлаган тагын да кыз-кияүләре бар Шамил аганың. Әтиләренең туган көненә барысы да җыелышкан иделәр алар. «Үзебез өлкәнәеп килсәк тә, әти киңәшеннән башка бер эш тә эшләгәнебез юк, – диләр кызлар. – Әтинең үгет-нәсыйхәтләре белән башлаган эш һәрвакытта уң була. Бу инде безнең тарафтан сыналган», – дип сүзгә кушылды кияүләр дә.

Юбилярны котларга башкарма комитет җитәкчесе Данис Сатдинов та килде. Ул Шамил агага барлык хезмәтләре өчен рәхмәт белдерде. Россия Президенты Владимир Путинның котлау открыткасын, бүләкләр тапшырды.

Резеда ЖАМАЛЕТДИНОВА.
Чүпрәле районы

АВЫЛЫБЫЗ ГОРУРЛЫГЫ

Татар генераллары

Авиация генерал-лейтенанты Таһир Сәйфетдиновның тормыш сәхифәләре Азнакай районы Югары Стәрле авылы белән тыгыз бәйләнгән, балачагыбыз да күпчелек бергәләп үтте. Әтисе Әгъзәй абыйның өй-ихатасы безнең бакча артында ямьле Стәрле, Ык елгалары янәшәсендә иде. Әгъзәй абыйлар анда ишле бала-чага тәгәрәшеп үсеп, читкә таралышып бетсәләр дә, балалары-бәләкәчләре җәен гел шушы нигездә энесе, балта остасы Әнвәр абыйларның бәбкә үләнле иркен ишегалларында тулып яталар иде. Шул исәптән генерал буласы Таһир да анда. Без язгы кояш яланнарны ачканнан көзге тиклем, шәмәй уеннарыннан башлап, балык тота-тота, яланаяк чабыш-шаярып, балачакны бик күңелле үткәрдек.

Әтисе Әгъзәй абый исә сәүдә өлкәсендә эшләп, аннары Азнакайга күчеп, анда үз йортын җиткереп, районда беренчеләрдән булып читтән торып Мәскәүдә югары профсоюз мәктәбен тәмамлый. Ул – әтинең балачак дусты, классташы, башлап урта мәктәпне тәмамлыйлар, сугышка да бергә китәләр, кайчан карасаң, бер-берләреннән аерылмыйлар иде. Үзенең генерал улы белән чиксез горурлана иде Әгъзәй абый.

– Таһир үзебезнең Югары Стәрле авылында туып үсте, – дип сөйли иде ул. – Азнакай шәһәренең 2 нче урта мәктәбен тәмамлады. Физика, математика фәннәрен бик яратты, югары хәрби училищега укырга керде. 1984 елда Жуков исемендәге хәрби академияне тәмамлап, генерал-майор дәрәҗәсе алды. Тагын СССР Хәрби Көчләре Генераль штабы академиясендә, ягъни генерал дәрәҗәсенә ирешү өчен гомере буе белем алды. Улыбызга дивизия, корпус белән командалык итәргә туры килде. 1995 елда генерал-лейтенант званиесе бирелде. Соңгы хезмәте – Брянщина. Брянск гарнизоны начальнигы булып, биредә һава һөҗүменнән саклану корпусы белән командалык итте. Безнең горурланырлык, бик тә сөекле улыбыз иде ул. Юкка гына аның турында армия генералы Мәхмүт Гәрәев: «Таһир Сәйфетдинов кебек үзе сынаучы-очучы генераллар бик сирәк», – дип язып чыкмады.

Әгъзәй абый исә – утны-суны кичкән сугыш ветераны, күп орденнар кавалеры. «Мин Кызыл Йолдыз орденын Бөек Ватан сугышында дәһшәтле яуда алсам, улым аны тыныч тормышта алды», – дип ул дымлы күзләрен сөртеп куя иде. Җиңү яулап кайткач, шәһәребездә күп кенә җитәкче урыннарда эшләп лаеклы ялга чыга. Замандашы Габделхәй Рәхимов белән берсе җитәкче, икенчесе урынбасар булып, район ветераннар советы үзегендә кайныйлар. Ә хатыны Зифа апа гомере буе балалар укыта, мактаулы исемнәргә лаек була.

Соңгы тапкыр без Әгъзәй абый һәм җәмәгате Зифа апа белән 2010 ел башында шәһәребезнең төбәкне өйрәнү музеенда очрашкан идек. Очрашуны музейны оештыручы-директор Гөлсем Хисамиева ачып, ветераннар үткән даннлы юл турында сөйләгәч, төп игътибарны аларның улы – авиация генерал-лейтенанты Таһир Сәйфетдиновның хезмәт юлына юнәлтте. Генерал исән вакытта, кайткан саен, музейга керә торган була. Хәзер дә аның хәрби формасы, шәхси әйберләре биредә күренекле урында тора. Районыбыздагы ике генералның берсе – Бөек Ватан сугышы ветераны генерал-майор Фатих Булатов белән янәшә ул әйберләр. Таһир Әгъзәй улы 1980 нче елларда хезмәт иткән гарнизоннарның берсендә космик элемтәләр батальоны урнаша. Шуңа да якташ генерал космонавтлар, космик очышлар белән һәрчак хәбәрдар була. Музейда аның очучы-космонавт, Советлар Союзы Герое Леонид Кизим белән янәшә төшкән фотосурәте дә моны ачык раслый. Бу очрашуда Әгъзәй абый легендар улының балачагы һәм, гомумән, хәрби тормыш юлы турында бик дулкынланып сөйләгән иде. Монда Таһир Сәйфетдиновның класс җитәкчесе, СССР мәгариф отличнигы Евдокия Петровна Калинина генералның аңа язган хатларын укып, үзенең якты хатирәләре белән уртаклашкан иде. Классташы, районыбызда күп кенә җитәкче урыннарда эшләгән Габдрахман Убайдуллаев Таһир Сәйфетдинов белән һәрчак элемтәдә, дус яшәүләре турында бик мавыктыргыч хикәя итүе дә бүгенгедәй истә. Һәм тагын бик хәтердәгесе: очрашуда катнашучылар генерал якташыбызның исемен мәңгеләштерү өчен, ул үскән Ушанов урамын Сәйфетдиновлар яки генерал Сәйфетдинов урамы дип үзгәртү турында мөрәҗәгать белән чыксалар да, тик нигәдер моның һаман сүздән узмавы гына гаҗәпкә калдыра. Югыйсә бу бик тә җитлеккән, урынлы, мөкәммәл тәкъдим бит, җәмәгать! Үзебезне, үзебезнең генералларыбызны үзебез зурламасак, тагын кемнәр олылар, кадерләр соң?

Әсгать СӘГЫТДИНОВ,
ветеран-журналист.
Азнакай шәһәре

СИН – МИНЕМ ҖАНЫМНЫҢ ЯРТЫСЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гаиләдә һәрвакыт уңай мохит булырга тиеш, бер-береңә авыр сүзләр әйтмәскә, мөнәсәбәтләргә көнчелекне кертмәскә кирәк. Яраткан кешеңнән генә түгел, күрше, туган, якыннарыңнан да көнләшергә ярамый, ул – чир. Яшь парларга шуны әйтәсе килә: гаиләдә бер-береңне хөрмәт итеп, санлап яшәсәң, машина да, фатир да алып, йорт та салып була.

Һәр гаиләнең үз мәхәббәт тарихы бар, диләр. Фәризә апа белән Зиннур абый Закировлар икесе дә искиткеч матур табигатьле, үзләре сөйләве буенча биш чишмәле Аман-Оштырма авылыннан. Зиннур абый авылда төшеп калган егетләрдән булмый. Аның өздереп гармунда уйнавы гына да күп кызларның күңелләрен җилкетә, ә Фәризә апа авылның бер чибәре була.

– Мин яшь чакта Аллаһы Тәгаләдән никах вакыты килеп җитмичә, кызлар белән йөрмим дип, үземә сүз бирдем. Уенлыкларда кызлар битләремнән үбеп китсәләр дә, игътибар итмәдем, – диде Зиннур абый. – Көннәрдән бер көнне зифа буйлы, чибәр Фәризәгә күзем төшкәч, бар кыюлыгымны җыеп, кызны озатып куярга булдым. Үзем, яңакка сукмасын тагын дип, сакланып кына тордым. Юк, ул сүз әйтмәде. Ике ай тирәсе очрашып йөргәч, өйләнешергә сүз куештык. Алырга дип барсам, өендә юк. Иптәш кызында чәй эчеп утыра. Җитәкләшеп безгә кайттык, аяк астына җәйгән мендәрләргә кыю гына басып кереп китте, бу килен була инде, дидем.

Яшьләрнең тормышы авыр елларга туры килә. Яз көне басудан өшегән бәрәңге, комбайннан калган ашлык башаклары җыялар, кычыткан ашы пешерәләр. Әмма бу турыда артык сөйләнеп тормыйча, зарланмыйк, дип, сүзне икенчегә күчерәләр. Зиннур абый хезмәт юлын комбайнда башлап җибәрә, исеме алдынгылар тактасыннан төшми. Райсоюзда шофер була, үзе дә машина йөртүчеләрне укыта, «Сельхозхимия»дә инженер хезмәтен башкара, ә пенсиягә район газ оешмасыннан чыга. «Газда ул гына эшләмәде, мин дә эшләдем, – ди Фәризә апа, елмаеп. – Ун ел буе иртән торып, сумкаларын әзерләп чыгарып җибәрдем. Берсендә әйтмәгән идем, сумкасын онытып киткән. Янилгә барып җиткәндә кире борылып кайтты».

Фәризә апа исә – сугыш ятиме, аның әтисе, бер абыйсы яу кырында һәлак була. Кыз кечкенәдән әнисенә булышып, эшкә өйрәнеп үсә. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, Казан һөнәри-техник училищесында тегүчелек буенча белем ала, ул вакытта анда әтисез балаларны укырга җыя торган булалар. Укуын тәмамлап, туган якларына әйләнеп кайта, көнкүреш комбинатында пәлтә, күлмәк тегүдә эшли, бригадир була.

– Без яшь чакта авылда ике генә машина бар иде, шуның берсе – Зиннурда. Башта Кукмарага Хөрмәтулла абый белән йөрдек, аннан соң Зиннурның капка төбенә килеп баса идек. Бервакыт Казаннан җизниләр кунакка кайтты. «И-и, юлда бик әйбәт шофер туры килде, сикертмәде дә», – диделәр, Зиннурны мактап. Ул райсоюзда эшләгәч, алар ипи ашыйлар икән, дип сөйлиләр иде. Зиннур безне дә ярдәменнән калдырмады, сүземне күп тыңлады, – диде Фәризә апа, истәлекләрен барлап.

Шулай итеп, алар бергә гаилә коралар, өч кыз бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге көндә балалар, оныклары-ның кадер-хөрмәтен тоеп гомер итәләр.

– Кечкенәдән әти-әни арасындагы җылы мөнәсәбәтне тоеп, күреп үстек. Безне дә хезмәт сөяргә, кешеләрне яратырга, хөрмәт итәргә өйрәттеләр. Өйгә килгән кешене чәй эчертми чыгармадылар. Алар без – кызларына һәрвакыт «матурларым» дип кенә дәшәләр. Шуңа күрә үзебез дә алар үрнәгендә яшәргә тырышабыз, – диде кызлары Гөлфия Мирзагаянова.

Ризилә КОРБАНОВА.
Кукмара районы

Табигать нигъмәте

КУРА ҖИЛӘГЕ

Кура җиләгенең киптерелгәне дә, туңдырылганы да витаминнарын югалтмый. Салкын тигәндә киптерелгән кура җиләгеннән дә шифалырак җимеш юктыр, мөгаен. Аның составында глюкоза, фруктоза, органик кислоталар, пектин, C, D витаминнары бар.

Киптерелгән җимешне, чәй пешергән кебек үк, өстенә кайнар су коеп каплап торалар. Аны эчкәннән соң шунда ук җылы юрган бөркәнеп ятарга кирәк. Тир белән бергә организмнан чир дә, шлаклар да чыга.

Туңдыргычта кура җиләгенең витаминнары шул килеш саклана. Кышкы салкын көннәрдә кура җиләге яфрагы яисә сабагы салынган хуш исле чәй эчү ямьле җәйләрне генә искә төшереп калмый, организмны да ныгыта, тонусны да яхшыртып җибәрә.

vk.com

ҖИР ҖИЛӘГЕ

Җир җиләгендә пектин, шикәр, дуплау матдәләре, тимер, кальций бар. Ул лимон һәм алма кислотасына, C витаминына бай. Җиләк аппетитны, хәтерне яхшырта, су эчәсе килүне баса, ашкайнату процессын яхшырта, матдәләр алмашын, кан басымын көйли. Җиләкне кышка киптереп куйганда, тирләтү чарасы буларак кулланырга була, салкын тигәннән дә файдасы бар. Халык табиблары, җиләк гипертония, эчәклек белән проблемалар булганда булыша, диләр. Җиләкне яман шешне булдырмау максатыннан да ашарга кирәк.

Сихәтле сок

Әлеге сокны ясау өчен бер чөгендер, ике кишер һәм бер алма кирәк. Юып, чистартып, барысын бергә салып, сок ясарга кирәк. Аның мондый авырулардан файдасы бар:

- яман шеш күзәнәкләре үсешен тоткарлый;
- бавыр, бөер, ашказаны асты бизе, ашказаны җәрәхәте авыруларын кисәтә;
- үпкәләрне ныгыта, йөрәк өянәгенә һәм югары кан басымыннан саклый;
- иммун системасын ныгыта;
- күз авыруларын кисәтә, күз кибү, кызару, арпа чыгуны булдырмый;
- мускуллар авыртканда, авыр физик хезмәттән соң файдалы;
- токсиннарны чыгара, эчне йомшарта, тирене матурайта, сафландыра;
- авыздагы начар исне бетерә;
- ябыгырга теләүчеләр өчен дә файдалы.

Әлеге сокның зыяны юк. Ике атна рәттән эчсәгез, хәлегезнең ничек яхшыруын шундук сизәрсез. Сокны сыгу белән эчәргә кирәк.

vk.com



Нияз Бишбалта

ЖАВАПЛАР. **Горизонталь буенча:** мук, башлау, алу, сер, ага, тилгән, Буа, мәк, Ык, урт, кар, тантана, коену, тар, кыңгырау. **Вертикаль буенча:** Муса, титаник, убыр, карама, куян, булат, кыр, ОКА, кыяр, еру, әрә, арена, урман, кием, ут.

Һәр өйдә булырга тиешле 5 гөл

1 АЛОЭ

Бу гөлнең яфраклары бүлеп чыгарган махсус матдәләр агуларны йота. Төнлә алоэ кислород ясый. Алоэ суы ярдәмендә томау төшүне, ашказаны авыруларын дәвалыйлар.

vk.com

2 ЯРАН ГӨЛ

Аннан ясалган компресс белән элекке заманда томау, колак сызлавын, баш һәм мускул авыртуларын дәвалаганнар. Бу матур үсемлекнең чәчәкләре кызыл, ак, алсу төстә. Үзеннән үзенчәлекле ис килә. Яран гөл бүлмәдәге һаваны яңарта, микроблар һәм артык дым белән көрәшә. Ә җәен чебеннәрне куркыта. Бу гөл кухня, йокы бүлмәсе өчен яхшы. Яранның исе кан басымын төшерә, йоклый алмый интеккәндә булыша.

vk.com

3 ХЛОРОФИТУМ

Тиз үсә, артык тәрбия сорамый. Әллә нинди кыйммәтле кондиционердан да яхшы итеп бүлмә һавасын чистарта. Хлорофитум зыянлы бактерияләрне юк итә, стенада барлыкка килүче гөмбә, күгәреккә дошман булып тора. Бу гөл һәр аш бүлмәсендә үсәргә тиеш. Ул һавада булган зыянлы матдәләрнең 80 процентын юк итә.

vk.com

4 СПАТИФИЛЛИУМ

Стресстан булышучы матдәләр бүлеп чыгара, һаваны чистарта һәм дымландыра. Ул микробларны гына түгел, аммиак, бензол, ацетон һәм башка спирт парларын йота.

vk.com

5 КАКТУС

Аны йокы һәм бала бүлмәсеннән ерак тотыгыз. Аның урыны – эш бүлмәсендә. Ул компьютердан чыккан нурланышларны йота.

vk.com

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 13 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru